| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Азевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Азево авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.07.2024 Азево авылы № 46-1

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Азево авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Азево авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варисларның берсе дә мирас алудан читләштерелмәсә, яки варисларның берсе дә мирас алудан титләтерелгән, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) Салым түләүченең - гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән соң өч ел вакыт узу;

4) гамәлдән чыгарылган җирле салымнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

5) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

6) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып тора:

1) әлеге карарның 1 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда: а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе; б) вафат булуга бәйле рәвештә салым органнарында исәпкә алынганнан соң физик затны төшереп калдыру турында белешмәләр; в) мираска хокук турында таныклык бирү турында белешмәләр булмау турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге карарның 1 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда: а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе; б) салым түләүченең - гражданнарның стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы турында белешмә;

3) әлеге карарның 1 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда: а) салым органының физик затның бурычы суммасы турында белешмәсе; б) физик затның мөлкәткә милек хокукын туктату турында салым органы белешмәсе, ул салым салу объекты булып тора;

4) әлеге карарның 1 статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән нигез булганда: а) салым органының бурычны барлыкка китерү чорын аңа кушып бирелгән пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммалары турында белешмәсе;

5) әлеге карарның 1 статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән нигез булганда: а) индивидуаль эшкуарның статусын югалткан оешманы, индивидуаль эшкуарны, физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органы белешмәсе; б) салым бетерелгән норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында белешмәләр;

6) әлеге карарның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда - салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч барлыгы турындагы белешмәсе.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының веб-адрес буенча хокукый мәгълүматның рәсми порталында хәбәр итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Әгерже муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының Азево авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы — В.С.Семенов